# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Кызыл Бакча авылында 2021 елда үзара салым кертү турында

**19.11.2020 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пунктында яшәүче гражданнар җыены

**Карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан тыш; җирлек территориясендә яшәүче гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк), авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан кала. 300,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Кызыл Бакча торак пунктында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне ремонтлау, (төзелеш материаллары сатып алу, мемориаль плитәләр, буяу, брусчатка, пьедесталны ремонтлау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча авылында мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru)да кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлек башлыгы Р. Ә. Кәримов